Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә
авыл җирлеге башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«30» гыйнвар 2024 ел. № 1

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр кыйммләтен раслау турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль закон, 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы "Җирләү һәм җирләү эше турында" Федераль закон, 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы "Татарстан Республикасында күмү һәм җирләү эше турында "Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында" Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карары, 2024 елның 23гыйнварындагы 46 нче номерлы " 2024 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында" Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әтнә мунципаль районының Югары Сәрдә авыл җирлегендә № 1 нче һәм № 2 нче кушымта нигезендә җирләү буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелгән хезмәт бәясен 8370,2 сум күләмендә билгеләргә һәм 2024 елның 1 нче февраленнән гамәлгә кертергә.

2. Югары Сәрдә авыл башкарма комитетының 2023 елның 31 январендәге 1 номерлы «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр кыйммәтен раслау турында»гы карарын 2024 елның 1 февраленнән үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы Әтнә
муниципаль районы Югары Сәрдә
авыл башкарма комитеты җитәкчесе Р.Р.Хөснетдинов

Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл башкарма комитетының 2024 елның 30 гыйнварындагы 1 нче номерлы карарына 1 нче кушымта

2024 елның 1 февраленнән җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр бәясе исемлеге

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
| --- | --- |
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Табут һәм башка күмү өчен кирәкле предметларны бирү һәм китерү | 5542,3 |
| 3.Зиратка үлгән кешенең мәетен (җәсәдләрен) илтү. | 669,31 |
| 4. Күмү (кабер казу һәм күмү) | 2158,59 |
| **Барлыгы** | 8370,2 |

Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл башкарма комитетының 2024 елнын 30 гыйнварындагы 1 нче номерлы карарына 2 нче кушымта

2024 елның 1 февраленнән җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр бәясе исемлеге

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Мәетне кәфенләү | 301,18 |
| 3. Табут һәм башка күмү өчен кирәкле предметларны бирү һәм китерү | 5241,12 |
| 4. Зиратка үлгән кешенең мәетен (җәсәдләрен) илтү. | 669,31 |
| 5. Күмү (кабер казу һәм күмү) | 2158,59 |
| **Барлыгы** | 8370,2 |